БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» 12 2022 ел № 376

**Гражданнарны җир кишәрлекләрен милеккә бушлай алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32.1 статьяларына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә һәм Балтач районы прокуратурасының 2022 елның 16 сентябрендәге 02-08-01/Прдп169-22-20920011 номерлы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 6 октябрендәге 319 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- карарның преамбуласында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән» сүзтезмәсен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 6 октябрендәге 319 номерлы карары белән расланган гражданнарны җир кишәрлекләрен милеккә бушлай алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 2.4 бүлекнең 2.4.1 пунктындагы 1 абзацта «бакчачылык яисә яшелчәчелек» сүзләреннән соң «, әгәр мондый гражданнар җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән көнгә кадәрге биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәсәләр һәм социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптә торсалар» сүзләрен өстәргә.

2.2. 2.4 бүлекнең 2.4.1 пунктындагы 1 абзацта

- «аларны исемлеккә керткән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга,

- «бакчачылык яисә яшелчәчелек» сүзләреннән соң «, әгәр мондый гражданнар җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән көнгә кадәрге биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәсәләр һәм социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптә торсалар» сүзләрен өстәргә.

2.3. 2.4 бүлекнең 2.4.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гражданнарны исемлеккә кертүдән баш тарту турында хәбәр итү җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән алып җиде көннән дә соңга калмыйча тапшыру турында хәбәрнамәле заказлы хат белән яисә хәбәр кәгазен имза куйдырып бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.».

2.4. 2.5 бүлекнең 2.5.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9 һәм 10 пунктчалар өстәргә:

«9) мөрәҗәгать итүченең социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынга мохтаҗ буларак исәптә торуын раслый торган документ;

«10) мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәрге биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын билгеләү турында суд карары (мөрәҗәгать итүченең паспортында җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәрге биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү турында тамга булмаган очракта).».

2.5. 2.5 бүлекнең 2.5.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әгәр мөрәҗәгать итүче аны үз инициативасы белән тапшырмаган булса, әлеге пунктның 9 пунктчасында күрсәтелгән документ җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә соратып алына.».

2.6. 2.8 бүлекнең 2.8.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

«социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптән төшерү.».

2.7. 2.8 бүлекнең 2.8.2 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) җир кишәрлеген сайлау процедурасында гражданнарның өч тапкыр җир кишәрлеген сайлаудан баш тартуы, яисә җир кишәрлеген сайлау процедурасына гражданнарның өч тапкыр килмәве, яисә гражданнарның җир кишәрлеген сайлау процедурасында җир кишәрлеген сайлаудан баш тарту һәм аларның җир кишәрлеген сайлау процедурасына килмәү очракларының гомуми саны өчкә тигез;».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов